**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТЧЕРЕМШАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица М.Титова, дом 7, Черемшан село, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс 8(84396)2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

**03.07.2020** **№ 198**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 августындагы 136 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән районы прокурорының 2020 елның 24 мартындагы 277-р номерлы Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә ризасызлыгын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2020 елның 17 мартындагы 191 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 августындагы 136 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 29 августындагы 136 номерлы карары белән (2018 елның 26 апрелендәге 124 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы «Чирмешән

муниципаль районы «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:
2.1. 3.6.1. бүлекнең 2 пунктчасын бәян итәргә: «2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:
а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу;
б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә катнашудан, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы вәкиленең рөхсәте белән;
в) «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;
г) муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә;
д) федераль законнарда каралган башка очраклар».
- түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктын өстәргә: «2.1. Эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә».
2.2. 7.2.3 бүлекне бәян итәргә: «Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш».
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
Советы Рәисе Урынбасары М.В. Кандрова